**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Учаллинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Советская, д. 51 , село Учалле,
Азнакаевского муниципального района, 423317
Тел. (факс) (85592) 36-8-32
Uchal .Azn @tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Совет урамы, 51, Үчәлле авылы
Азнакай муниципаль районы, 423317
Тел. (факс) (85592) 36-8-32
Uchal .Azn @tatar.ru

---

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«20» октябрь 2020ел. №5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Текмәле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам**:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Темәле авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2020 елның 31 октябрендә 14 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә;

2.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Текмәле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар Җыенын уздыру вакыты-2020 елның 31 октябрендә 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;

- Халык җыенын үткәрү урыны-Темәле авылы, Ишкәй урамы, 15 нче йорт яны;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 21 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетында

гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 йорты; Текмәле авылы, Ишкәй урамы, 15 йорт.

- сайлау хокукына ия булган Текмәле торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

-Текмәле пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 Үчәлле авыл җирлеге Текмәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 200 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Текмәле авыл җирлегенең урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Җирле әһәмияткә ия булган Текмәле автомобиль юлларын карап тоту: Ишкәй урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу һәм/яки ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү).

- Күмү урыннарын карап тоту (материал сатып алу, хуҗалык инвентаре саклау өчен йорт урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Җирлек территорияләрен төзекләндерү (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре күрсәтү;);

- Текмәле авылы зиратында контейнер мәйданчыклары урнаштыру, контейнер, киртәләр алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру ,нигез салу, коймалар урнаштыру);

- Җирлек территориясеннән каты коммуналь калдыкларны чыгару.

ӘЙЕ КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт; Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Текмәле авылы, Ишкәй урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә;

-Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

-Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык Г.М.Төхвәтуллина